ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» ноября 2022 ел №300

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» 20.07.2022 елның 162 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Балигъ булмаганнарга аерым товарлар сатуны чикләүне билгеләү өлешендә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 2 ноябрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы нигезендә, административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 8.1 статьясының 14, 16 өлешләренә таянып, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 11.11.2022 елның 11/13-09/5725 номерлы хатын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» 20.07.2022 елның 162 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының карарына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны вакытлы матбугат басмасында – «Татмедиа» АҖ филиалы Әгерҗе районының «Әгерҗе хәбәрләре» газетасында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат

рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **Р.Р. Шәрипов**

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Башкарма
комитетының
29.11.2022 № 300
карары белән расланды

**«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» 20.07.2022 елның 162 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының карарына үзгәрешләр**

| ТР Административ хокук бозулар кодексы статьялары | Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар кодексы нигезендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге | ТР Административ хокук бозулар кодексы нигезендә ведомство буйсынуындагы административ хокук бозулар турындагы эшләрне тикшерергә вәкаләтле органнар |
|---|---|---|
| **2.19. статья.** Балигъ булмаганнарга тонусны күтәрә торган алкогольсез эчемлекләрне ваклап сатуны чикләүне үтәмәү | - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисадый үсеш бүлеге башлыгы һәм баш белгечләре | Татарстан Республикасы Әгерҗе суд районы буенча 1 нче, 2 нче суд участоклары җәмәгать судьялары (7.1 статья. ТР Административ хокук бозулар турындагы кодекс) |
| **2.20. статья.** Балигъ булмаганнарга гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен киметелгән углеводород газы булган товарларны ваклап сатуны чикләүне үтәмәү | - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисадый үсеш бүлеге башлыгы һәм баш белгечләре | Татарстан Республикасы Әгерҗе суд районы буенча 1 нче, 2 нче суд участоклары җәмәгать судьялары (7.1 статья. ТР Административ хокук бозулар турындагы кодекс) |